# «Кырмыскалык»

буягыч - өстәл уены



2 уенчыдан алып 4 уенчыга кадәр
5+ яшьлек балалар өчен

Уенның төп максаты - балаларны кырмыскаларның үзтотышы белән таныштыру, аларда әлеге гаҗәеп бөҗәкләргә кызыксыну уяту.

**Ниләр кирәк булачак:**

1. Кайчы.
2. Җилем.
3. Төсле карандашлар (кызыл, зәңгәр, кызгылт сары, яшел).
4. Фишкалар яки төймәләр, уен шакмагы.
5. Принтер һәм кәгазь А4.

**Уенны ничек ясарга?**

1. Уенны принтердан чыгарыгыз (4 бит). Уенны төгәл итеп бастырып чыгару өчен, «**Принтер**» диалог тартмасында, «**Настройка размера и обработка страниц**» пунктында «**Подогнать**» төймәсен сайлагыз.




2. Уенның аскы өлешен тәшкил иткән чирекләрнең өске ак җирен кисегез.
3. Уенның ике сул һәм ике уң өлешләрен берләштерегез.
4. Килеп чыккан өлешләрне янә берләштерегез.
5. 1 алып 89 кадәр түгәрәкләрне карандашлар белән буягыз. Фломастерлар белән буясагыз, түгәрәкләрдәге саннар күренмәскә мөмкин, шуңа күрә, зинһар, фломастерлар кулланмагыз.

**Кызыл**
14, 21, 34, 70, 87
**Зәңгәр**
8, 32, 47, 54, 62, 75, 78
**Кызгылт сары**
3, 10, 16, 24, 28, 39, 40, 41, 46, 51, 58, 63, 67, 73, А, В, 81, 85
**Яшел**
4, 9, 12, 31, 38, 48, 60, 65, 88

**Кагыйдәләр:**

**Кызгылт сары** – йөреш юк.
**Зәңгәр** – алга сикерү (нокталар буенча).
**Кызыл** – артка чигенү (нокталар буенча).
**Яшел** – өстәмә йөреш.
69 ноктасындагы тукталыш = альтернатив юл (А-Е хәрефләре).



## Уеныгыз күңелле узсын!

# Рәхмәт сүзләре

«Кырмыскалык» буягыч-уенын Маша Кирикова уйлап тапты һәм рәсемгә төшерде. Уенны булдыруда «Түбән Кама» милли паркы хезмәткәрләре, хайваннар үзтотышы экологиясе лабораториясе мөдире, мирмеколог, биология фәннәре докторы, профессор Ж. И. Резникова (хайваннар систематикасы һәм экологиясе институты, Россия фәннәр академиясенең Себер бүлеге (ИСиЭЖ СО РАН)), умырткасызлар экологиясе лабораториясе мөдире, мирмеколог, биология фәннәре докторы Т. А. Новгородова, Казан (Идел буе) федераль университетының Зоология музее директоры А. Н. Беляев һәм Яр Чаллы шәһәренең 4нче санлы экология һәм биология үзәге катнашты.

«Друзья заповедных островов», «Заповедники» экоүзәге, Алабуга районының (Татарстан Республикасы) балалар өчен каралган экология һәм биология үзәгенә, «Татнефть» җәмгыятенә һәм уенны татар теленә тәрҗемә иткән «Гыйлем» фән һәм мәгърифәт үзәгенә рәхмәтләребезне белдерәбез.



Управление образования
Исполнительного комитета
муниципального образования
город Набережные Челны